**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чалпы авыл җирлеге Советы**

Чалпы авылы №154 «23» сентябрь 2019 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Чалпы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

2018 елдагы, 2019 елнын 1 нче январь көненә калган үзара салым акча калдыкларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү: «Чалпы, Камышлы, Ирекле, Балан-Бүләк авылларында көнкүреш калдыкларын, чүп-чарны җыю, чыгару һәм үтилләштерү» юнәлешеннән Чалпы авылында Ленин урамына, Яшьләр урамына, Бакчалы урамына, Яңа урамына, Гагарин урамына, Казан урамына, Балан-Бүләк авылында Ленин урамына, Камышлы авылында Яшьләр урамына, Ирекле авылында Гагарин урамына, Наратлы урамына «Вак таш җәелгән юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) » кебек сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карар «Маяк» район газетасында – рәсми басмада басылып чыгарга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http:// aznakyevo.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

Рәис: А.М.Мөхәммәтшин